# КАРАР

**Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Киекле авыл җирлеге Кизләү авылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

«30» март 2021 ел № 3

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2021 елның 30 мартында узган халык җыены нәтиҗәләре белән түбәндәге сорау буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде: «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Киекле авыл җирлегенең Кизләү торак пунктында 2020 елның 24 ноябрендә кабул ителгән 5 номерлы элек расланган гражданнар җыены нәтиҗәләре турында карарга һәм Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Киекле авыл җирлегенең Кизләү авылында халык җыенының 24.11.2020 ел, № 6 карарына түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү белән килешәсезме?:

Киекле авыл җирлеге Кизләү авылы территориясендә теркәлгән һәм яшәүче 1 төркем инвалидлардан, балачактан инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан кала, балигъ булган һәр кешедән, 2021 елда 1000 сум күләмендә җыелган үзара салымны югарыда күрсәтелгән карарлар белән расланган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерелергә мөмкин булган эшләр исемлеген түбәндәгечә бәян итәргә:

- халыкның янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү өчен товарлар сатып алу (янгын гидрантларын ремонтлау һәм чистарту), Кизләү авылында (алга таба анда янгын сүндерү машинасын тоту максаты белән) гараж өчен кирәкле товарлар (эшләр, хезмәт күрсәтүләр) сатып алу;
- Кизләү авылы территориясен төзекләндерү һәм карап тоту өчен товарлар сатып алу (эшләр, хезмәтләр).

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

җыенда катнашучы сайлау хокукына ия булган гражданнар исемлегенә 476 кеше кертелгән, җыенда тавыш бирүдә 355 кеше катнашты.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«ӘЙЕ» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 269 кеше тавыш бирде;

«ЮК» позициясе өчен җыенның 86 катнашучысы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Киекле авыл җирлеге Кизләү авылы торак пунктында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Киекле авыл җирлегенең Кизләү торак пунктында 2020 елның 24 ноябрендә кабул ителгән 5

номерлы элек расланган гражданнар җыены нәтиҗәләре турында карарга һәм Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Киекле авыл җирлегенең Кизләү авылында халык җыенының 24.11.2020 ел, № 6 карарына түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү белән килешәсезме?:

Киекле авыл җирлеге Кизләү авылы территориясендә теркәлгән һәм яшәүче 1 төркем инвалидлардан, балачактан инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан кала, балигъ булган һәр кешедән, 2021 елда 1000 сум күләмендә җыелган үзара салымны югарыда күрсәтелгән карарлар белән расланган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерелергә мөмкин булган эшләр исемлеген түбәндәгечә бәян итәргә:

- халыкның янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү өчен товарлар сатып алу (янгын гидрантларын ремонтлау һәм чистарту), Кизләү авылында (алга таба анда янгын сүндерү машинасын тоту максаты белән) гараж өчен кирәкле товарлар (эшләр, хезмәт күрсәтүләр) сатып алу;

- Кизләү авылы территориясен төзекләндерү һәм карап тоту өчен товарлар сатып алу (эшләр, хезмәтләр)» мәсьәләсе буенча карарны кабул ителгән дип танырга.

3. Халык җыены нәтиҗәләрен «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталы»нда, Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Киекле авыл җирлеге Кизләү авылы мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Киекле авыл җирлеге тарафыннан кабул ителгән әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче: Р.Ә.Заһертдинова

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Киекле авыл җирлеге башлыгы
вазыйфаларын башкаручы Р.Ә. Заһертдинова